ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» мая 2021 ел № 132

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелеше күренешен килештерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварындагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, тәңгәлсезлекләрне бетерү һәм аны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына һәм норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелеше күренешен килештерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварындагы 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 5.3 пунктын төшереп калдырырга;
- 5.4 пунктын 5.3 пункты дип санарга;
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештереп, ведомствоара комиссия төзү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелеше күренешен килештерү буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 1 нче кушымтасында Молчанова Лилия Тимурхановнаны төшереп калдырырга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма

комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы Заитова Аида Салих кызын кертергә.

3. Әлеге карарны Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**